СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

10сентябрь, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 101 (8113) | Бәясе билгеләнгәнчә

# Иген икмәк - көн күрмәк

## Бодай була болай булса

Районыбыз игенчеләре быел дәүләткә килешү йөкләмәсендәгедән тыш ашлык озату буенча киеренке эш алып баралар. Кичәге көнгә дәүләт амбарларына 65 мең тоннадан артык ашлык салынды инде. Шунысы куанычлы, моның 41 мең тоннадан күбрәге - яхшы сыйфатлы ашамлык бодае.

«Таң» крестьян кооперативлары берлеге игенчеләре дәүләткә бодай тапшыру буенча күтәренке заданиене районда иң беренче булып тугырдылар - биредән элеваторга 1100 тоннадан артыграк яхшы сыйфатлы ашамлык бодае керде инде. Кичә «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыгы да бу төр мөһим заданиене тутырды - хуиҗалык дәүләт амбарларына 2 мең тоннага якын бодай озатты.

Ашлыкны дәүләт амбарларына саклауга салу уңышлы дәвам итә.



Мичурин исемендәге КХАда эшләүче Николай Васильевич Маськинны язмыш Самара өлкәсендә яшәп, эшләргә мәҗбүр итте. Ләкин туган яклары һаман да үзенә тартты. Менә 12 ел инде тракторда эшли. Үзенә тапшырылган техниканы ипле карый, эш сөючәнлеге белән дә хезмәттәшләре арасында да хөрмәт казанды. Аның производство күрсәткечләре дә һәрвакыт әйбәт, быелгы язда 434 гектар җирдә чәчү үткәрде, шуннан күбрәк җирне киләсе уңышка әзерләде. Хуҗалыкта урып - җыю үзвакытында барып, ындыр табакларында алтынсу бөртекләр өеме арткан саен шатлана: гомуми эштә аның да өлеше бар.

**Рәсемдә: Мичурин исемендәге КХА тракторчысы Н.Маськин.**

## «Урак - 97» пресс - үзәге хәбәр итә

Район авыл хуҗалыгы идарәсеннән алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, 9 сентябрьгә бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культураларның 41.997 гектары, ягъни 85 проценты урып - җыелды. «Кондырча», «Рассвет» ассоциацияләрендә һәр гектардан алынган уртача уңыш 59,3 - 52,3 центнер тәшкил итә. «Родина»да ул 45.9 , Кузнецов исемендәге КХАда 46,6 центнер.

Шушы көнгә район буенча 84.680 центнер орлык хәзерләнде. Бу - планлаштырылганның 82 проценты кадәр. Хуҗалыкларның байтаклары үзләрен чәчүлек материал белән тәэмин итсәләр, «Татарстан», «Чирмешән» һәм сөт - май комбинаты, шикәр заводы, МСОның ярдәмче хуҗалыкларында орлык запасы планлаштырылганның 38 - 54 проценты күләмендә генә хәзерләнде әле.

9 сентябрьгә барлыгы 22.446 гектар (планның 36 проценты кадәр) мәйдан тунга сөрелде. «Якты Күл», «Рассвет», «Тан», «Дуслык» хуҗалыкларында бу эш әйбәт оештырылган. Ә менә «Татарстан», «Үрнәк», «Комбайн», «Игенче» хуҗалыкларында бу эш билгеләнгән кадәр мәйданнарның 17 - 25 процентында гына башкарылды. Нефтебаза һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында да тунга сөрү темпы канәгатьләнмәслек.

Уңышы җыелган мәйданнарның 34.436 гектарыннан салам җыелды һәм ул 36.246 тонна күләмендә эскерткә куелды. Шулай итеп, салам запасы планлаштырылганның 54 проценты кадәр тупланды.

9 сентябрьгә кукурузның 3.542 гектары, ягъни яртысына якыны урып - җыелды. 40.751 тонна силос салынды.

## Рәшит алдынгылыкны бирми

«Алга» КХАнан **Рәшит Кәлимулла улы Насыйбуллин** «ДОН - 1500» комбайны белән 23.120 центнер ашлык суктырды.

Хафизов исемендәге хуҗалыктан **Александр Егорович Донсков** шундый ук комбайн бункерыннан 17.992 центнер ашлык бушатты.

МТСның җыелма отрядыннан «Кейс» комбайнчылары **Александр Николаевич Виноградов һәм Алексей Петрович Федоров** 20.147, **Виктор Михайлович Прохоров һәм Алексей Сергеевич Белогубов** 19.569, **Фәрит Сәлихович Җәлалов һәм Фәнис Галимович Гаязов** 19.205 центнер ашлык суктырдылар.

Мичурин исемендәге КХАдан **Иван Валерьянович Николаев һәм Алексей Ильич Исаев** «Нива» комбайннары бункерыннан 13.552 - 12.832 центнер ашлык бушаттылар.

### Авылда эш кызу

## Ветеран быел да сынатмый

«Заветы Ильича» хуҗалыгының атаклы комбайнчысы Юрий Алексеевич Гордюнин үзенең «ДОН -1500» комбайнын быел районда иң беренче булып ашлык суктыруга алып чыккан иде. Ветеран комбайнчы урак башыннан бирле хуҗалыкта алдынгылыкны бирмичә тырышып эшли. Шуңа да хуҗалыкның үз комбайнчылары арасында иң күп суктырылган ашлык ярдәмчесе Виталий Ворков белән эшләүче шушы ветеран экипажы исәбендә.

Хуҗалыкның алдынгы шоферлары Анатолий Николаевич Шубин белән Борис Харисанович Ворков кырдан ындырга ашлык ташуда алдынгылыкны бирмиләр - аларның беренчесе ГАЗ - 53 белән 7700 центнердан күбрәк, икенчесе ЗИЛ машинасында 6800 центнердан артык ашлык ташыдылар инде.


## Салам урыны эскерттә

Хуҗалыгыбызда уңышы җыелган мәйданнардан салам җыю эше әйбәт оештырылган. Икенче комплекслы бригадада, мәсәлән, бу эш аеруча зур оешканлык белән бара. Тәҗрибәле механизатор Габдулла Гайсин «Белорусь»ка көйләнгән агрегат ярдәмендә саламны эскерткә куя. Фәнил Вәлиев, Талип Хәлилов, Рафаэль Мотаһиров, Рәис Гатин исә эскерт башында саламны тигезләп торалар.

Фәрит Насыйбуллин белән Гадел Гайнетдинов өчен дә эш җитәрлек бүген. Механизаторлар ДТ - 75 тракторы белән басудагы саламны җыеп, эскертләргә куялар. Һәркем зур тырышлык белән эшли.

**С.ФӘТХЕТДИНОВА,**
**хәбәрче.**
**Яңа Әмзә авылы.**

## «Безнең атлар алар!»



«Кондырча» хуҗалыгында асрала торган атларның даны республика чикләрен күптән узып китте. Әле менә җөмһүриятебез башкаласында II нче Бөтендөнья татарлар конгрессы һәм Татарстан бәйсезлегенең 7 еллыгы уңаеннан үткәрелгән ярышларда да безнең атлар мөмкинлекләренең чиксез булуын тагын бер кат расладылар. Анда «Кондырча»дан 4 ат катнашты. Чиста нәселле чабышкылар арасында «Ледок» кушаматлы ат зур өстенлек белән беренчелекне алып, аның тренеры Я.Х.Балурев «Ока» машинасына лаек булды.

«Кондырча»ның «Дархан» кушаматлы аты исә лаеклы рәвештә өченче була. Башкала ярышларында катнашкан калган ике атның да нәтиҗәләре ярыйсы була.» Заманчивый»,мәсәлән, ярымфинал ярышларында 1600 метрны 2 минут 11 секунд эчендә үтеп,юртаклар арасында өченче нәтиҗә күрсәтте.

Республикада үткән мөһим вакыйгалар көннәрендә Әлмәт шәһәрендә дә узды ярышлар. Анда безнең районнан 5 ат катнашты. Район хакимиятенең «Альби» кушаматлы аты чиста нәселле чабышкылар арасында икенче нәтиҗә күрсәтте.

Атлар ярышлары сезоны дәвам итә. Районның танылган чабышкылары озакламый Чаллыда үтәчәк традицион «Аргамак-97» ярышларында катнашачаклар.

## Кыска хәбәрләр

### ЯҢА «АШЫГЫЧ ФОТО»

Ашыгыч рәвештә фоторәсемгә төшәргә кирәк булса кая барырга? Элек бу нәрсә проблема иде. Быелгы елның сентябреннән бу мәсьәләне җиңел хәл итеп булачак. «Надежда» дәүләт предприятиесе үзенең Школьная урамында урнашкан көнкүреш йортында «Ашыгыч фото» цехын ачты. Бирегә ике сәгать эчендә теләсә нинди үлчәмдәге фотоны ясап, кулыңа тоттыралар.

### ИКЕ ТУКТАЛЫШ АРАСЫ...

Шәһәр үзәгеннән аэропорт ягына автобус белән барганда, РСУга төшеп калу өчен стадион тукталышында төшеп ярты чакрым автобус артыннан теркелдәргә, я булмаса узып китеп базар тукталышына төшеп шул кадәр араны кире атларга кирәк. Бу ике тукталыш арасында биш оешма: РСУ, товар конторасы, НГЧ, нефтебаза, «Сельхозтехника» АТПсы урнашкан. Биш оешма өчен бер тукталыш ясап булмыймы икән?

**Ә.ГАБИТОВ.**

## Хөрмәтле дуслар!

**1997 елның 8 сентябреннән 1998 елның беренче ярты еллыгына газетага язылу игълан ителә. Язылу бәясе ярты елга 26.400, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**

***8 сентябрьдән 18 сентябрьгә кадәр «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газетасына льготалы язылу игълан ителә. Аның бәясе - 19.800 сум.***

Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.

# ДИСТӘ ЕЛГА ТОРЫРЛЫК БУ БЕР ЕЛ...

## *Менә шулай гадәти генә Норлатның яңа тарихы языла...*



1996 ел урак батыры Р.Насыйбуллин быел да 23 мең центнер ашлык суктырып республикада да алдынгы бара.



Район терлекчелек алдынгылары слетында САВУЧЫГА ТҮП КИЛЕШӘ?

«Реформалаштыруның нәтиҗәләре әле бар тулылыгында күренмәсә дә, беренче яртыеллык күрсәткечләре генә дә күп нәрсә турында сөйли. Малларны карау һәм ашатуга элеккеге күләмдә үк чыгымнар тотылган шартларда да район терлекчеләре дәүләткә ит сатуның яртыеллык планын 143, сөтнекен 163 процентка үтәделәр. Ит һәм сөт хәзерләү күләмнәре узган елгы дәрәҗәдән берьярым тапкырдан күбрәккә артты. Дәүләт ресурсларына сөт сатуның тулай күләме буенча Октябрь районы хуҗалыклары республикада беренче урынга чыктылар».

«Эш башында оста торса»

М.ЗАХАРОВ,

Татарстан республикасының атказанган икътисадчысы.



«КЕЛӘМДӘ БАТЫР УЛ ХЕЗМӘТТӘ ДӘ БАТЫ



*«- Ат - иң саф, иң изге хайван. Йөкче дә ул, аучы да, җир эшкәртүче дә, сугышчы да, спортчы да һәм матурлык та. Сирәк авырый, чире кешегә йокмый.»* Н.ГЫЙМАТДИНОВА.

*«Килешегез, әгәр кеше республиканың авыл хуҗалыгы министры постын калдырып үз теләге белән бурычлардан, җимереклек һәм эчкечелектән, хуҗасызлыктан гаҗиз калган районны аякка бастырырга алына икән - бу инде чын ир - ат, гражданин һәм патриот адымы.*

*Инде тулыр - тулмас 10 ай эчендә ул агрокүрсәткечләрнең күбесе ягыннан хәлдән тайган хуҗалыкны утыз фәләненче урыннан беренче урынга чыгара, промышленность эш кенә түгел - иртәгегә портфель тулы заказ җыя, яралгы хәлендә үк катып калган мәдәният үз лауреатлары исемнәре белән бөтен республикага яңгырый икән - бу тумыштан лидерның башлап юл салучының кызыксынуы, кешеләр язмышы өчен җаваплылык хисләре белән үстерелгән, ходай биргән байлыгы, талантлы.*

Т.ДРОНОВА.

«Бизнес - класс» регионара эшлекле газета, 13 август, 1997 ел.



РАЙОН ТАРИХЫНДА БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР ДӘҮЛӘТКӘ 65 МЕҢ ТОННА АШЛЫК ТАПШЫРЫЛДЫ ИНДЕ, АНЫҢ 41 МЕҢНӘН АРТЫГЫ - КЫЙММӘТЛЕ БОДАЙ.

**«Бу якларда бер табигать кенә җанланмаган, кешеләрнең дә бәйрәмгә җыенгандай, йөзләре нурланган, кем белән генә сөйләшмә, кемгә генә сүз катма, уртак сөенечләрен әйтергә ашыгалар. Алар районга яңа хакимият башлыгы аяк баскач, икенче төрле яши башлаганнар сыман. Без чын хуҗага тиендек, күрегез мондагы үзгәрешләрне, кыска гына вакыт эчендә аэропорт бинасы төзелде, очыш мәйданы ясалды, көн дә Казанга самолет күтәрелә, юллар салына, ничәшәр ай тоткарланган хезмәт хаклары бирелә һ.б. һ.б. диләр.» Н.Гыйматдинова,«ИДЕЛ» № 6**



*«Норлатлылар эшчән, тырыш, аллага шөкер. «Их, сине алкышлап каршы алган зал әле дә күз алдымда тора», - диде миңа Минтимер Шәрипович. Чынлап та, мине яратып кабул итте Норлат. Менә шушында туган кебек хис итеп яшим үземне.»*

Н.ГЫЙМАТДИНОВА.



«Ә даими су белән тәэмин итүнең (соңрак кайнар су белән дә, бойлерлар әзер) район елъязмасында үзенчәлекле юл булачагы - бәхәссез».

Т.ДРОНОВА.



«Дөньяда аларга (культиваторлар) тиңләнерлек техника юк - туфрак эшкәртү мөмкинлеге буенча да аңа басым ясау буенча да, техник һәм бәя характеристикасы ягыннан да».

Т.ДРОНОВА.



«Гомерне сүгелеп үткәрүгә караганда, макталып уздыруны артыграк күреп «Үзем өчен генә түгел бит»,- дип халыкка санап бетермәслек яхшылыклар эшли».

Х.БӘДРЕТДИНОВ,

.«Шәһри Казан» газетасы.



«Кешеләр дөнья күрсеннәр, үзләрен күрсәтсеннәр, яхшырак эшли башларлар, туган җирләренә ныграк берегерләр һәм фикерләүләре киңәер,- дип саный хаким. «Менә кая чылбыр сузыла: аэропорттан - патриотизм һәм рухи байлыкка, ә алардан районга һәм шәһәргә файда гына».

Т.ДРОНОВА.





Сильвестр атакай чиркәү ачылганда христианнар рәхмәтен үзе житкерде

РАЙОН ЕЛЪЯЗМАСЫ ДӘВАМ ИТӘ...

# Ни чәчсәң - шуны урырсың...



- Улым, мәктәбеңнән кайттыңмы? Кулларыңны ю да ашап ал...

- Кызым, ашап туйдыңмы? Амин тотарга, рәхмәт әйтергә онытма...

- Кил әле, улым, тәмле коймаклар белән чәй эчик...

Мондый сөйләшү нинди гаиләдә күбрәк була дисез? Тату гаиләдәме? Өлешчә дөрес. Ә иң дөресе - бу - әби - бабай белән яшәгән гаиләдә күбрәк янгырый. Әби - йортның йозагы сыман һәрчак өйдә: бу галәмәт тә эшле заманда ул оныкларын мәктәпкә озата, аннан каршы ала, өй эшләренә өйрәтә. Шул арада сиздерми, аптыратмый - ялыктырмый гына баланы әдәпкә, эшкә күндерә. Бабайлар исә күбрәк ир балалар янында булалар: печән чабарга кечкенә чалгыны ул ясап бирә, оныгын кулыннан тотып чүкеч белән эшләргә өйрәтә, терлек - туар янында эшләү күнекмәләрен индерә. Һәм, билгеле, бабай авызыннан чыккан акыллы сүз, кирәкле киңәш һич кенә дә онык колагын читләп үтми.

- Әби - бабайлы йортта балалар тәрбияле, тәртипле булып үсәләр, әхлакны таный, гореф - гадәтләрне хөрмәт итә торган булалар,- дип бертавыштан кабатлыйлар педагоглар да. Шуңа да соңгы елларда авылларда яшьләрнең төп йорттан аерылып башка чыгулары, бистә - бистә булып «котылдык» урамнары барлыкка килүне күтәреп - күтәреп мактаганда мәсьәләнең шул ягын күз угыннан ычкындыруыбыз үзен сиздерми калмады. Ата - анасы көне буе эштә булган, күзәтүсез үз ирегендә калдырылган балалар арасында җинаятьчелек тә арта торды, әхлак - әдәп якларының аксавы да үзен сиздерде. Аннары, гомер - гомергә төп йорт, туган нигез саналган ата - ана йортлары бушады, туздыды. (Элек - электән татарда төпчек ул нигездә калырга тиеш дигән канун, күрәсең, шуны да күздә тоткандыр). Нигез югалу - ул күпләрне туган җир белән бәйләп торган җепнең өзелүе белән бер: туганнар арасындагы элемтәне дә йомшарта, ата - ана дигән олы хакны да кадерсезгә калдыра сыман иде...

Авылга соңгы кайтуларның берсендә мәктәп директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары Р.З.Борһанова сөенеп:

- Авылда кайнана - кайната белән яшәүчеләр артты. Гөр килеп яшиләр, тәгәрәшеп балалары үсә. Без мәктәпкә тәрбияле балалар килә дип шатланып торабыз,- дигәч, алда язганнарга тагы бер кат инанып куйдым. Шулай икән шул. Әнә түбән очта механизатор Ринат белән сыер савучы Рәмзия Мусиналар әтиләре Гөлшат ага һәм әниләре Нәкыя апа белән гөрләп яшәп яталар, 2 балалары үсә. Алардан ерак түгел зур Минсафиннар гаиләсе яши. Өлкәннәр Могыйн ага белән Рәисә апа 40 ел әниләрен караган иделәр, инде үзләре балалары - уллары Мөнирһәм киленнәре Флюра хөрмәтендә яшиләр. Гаиләдәге өч бала әби - бабай сүзен ишетеп, кайгыртуын тоеп үсә. Мифтахов Касыйм ага һәм Сафия апа да Ринат һәм Әлфия белән бик тату гомер кичерәләр, кем белә, бу бәлки шулай ук тәрбия кылган әниләре догасы нәтиҗәседер?

Укытучылар Идрис һәм Рузалия Хөснетдиновлар да әти - әниләре Минһаҗ ага һәм Әкълимә апаны ташлап башка чыгарга теләмәделәр. Зур таш йорт җиткерделәр, җитеш тормыш белән яшиләр. Авылның иң уңган хатыннарыннан саналган ут кебек Әкълимә апа килен белән бер сүздә, бер киңәштә тормыш итә, җәй буе төп йорттан кунаклар өзелми. Ибраһимов Илгиз абый белән Флюра апа да киленнәре Гөлчирә, уллары Ильберт белән бөтен авылга үрнәк булырлык гомер кичерәләр. Гыйматдинов Илдус абыйлар, Шәкүров Габбас агалар гаиләсендә дә шундый ук татулык, бердәмлек, килешү. Яшьләр хуҗалыкта эштәнтуктамыйлар, әби - бабай - йорт йозаклары. Мәктәпкә бу йорттан әдәпле балалар киләсенә, киләчәктә алардан эшчән, мәгънәле кешеләр үсәсенә зур исәп тоталар. Ә әлегә бу йортлар туган нигез җылысын саклап, читтәге балаларны берләштереп, аларны авыл белән бәйләп тә торалар. Авылда калыккан яңа йортларда түр башында урын әби - бабайга бирелә икән, бу йортның яшь хуҗалары үз киләчәкләренә дә тәрбияле картлык, балаларының ихтирамын әзерлиләр ләбаса! Ни чәчсәң - шуны урырсың, диюләре шул бит инде.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**
Колбай Мораса авылы.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

10 нчы сентябрьдә кадерле әтиебез **Харис Исмәгыйль улы Әхмәтвәлиевкә** 70 яшь тула.

Кешеләргә игътибарлы, ачык йөзле, мәрхәмәтле әтиебез! Сине туган көнең белән чын күңелдән котлыйбыз. Сиңа исәнлек - саулык, яшәү куанычы һәм әниебез белән бергәләп озын гомер итүегезне телибез.

Гел шатланып яшә, әти, хәсрәт күрмә,
Тыныч булсын һәрчак күңелең.
Бәрәкәтле матур тормыш сиңа,
Кояшларга тиңе гомерең.

**Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, кызларың, кияүләрең, улың, килененң, оныкларың.**

## Белдерүләр

### САТАБЫЗ

«Локомотив» бакчачылык ширкәтендә дача участогы. **Тел.: 2 - 19 - 58, 17 сәг., тән соң.**

***

Стенка өчен яңа көзгеләр һәм пыялалар. **Тел.: 2 - 22 - 51.**

***

Шәхси йорт. **Спартак ур., 26, 18 сәг., тән соң.**

***

Ике бүлмәле фатир. **Тел.: 5 - 28 - 05.**

***

1996 елгы ВАЗ - 21093. **Адрес: Советская ур., 15 нче йорт.**

***

3,4 х 5 метрлы мунча бурасы. **Тел.: 2 - 21 - 89, 20.00 сәг., тән соң.**

### ТӨРЛЕСЕННӘН

Үз материалларыгыздан йортлар, гаражлар төзибез (арзан һәм сыйфатлы). **Тел.: 5 - 16 - 25, Нәҗип.**

***

**Төхфәтуллин Минзаһит Вәлиуллович** исеменә бирелгән 679061 номерлы югалган тракторчы таныклыгын гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

Кадерлебез Мифтахетдинов Вазыйх Һади улын соңгы юлга озатуда матди һәм мораль ярдәм күрсәткән, кайгыбызны уртаклашкан «Татнефть Норлатнефтегазразведка» ОООсы коллективына, профсоюз комитетына, УТТ профкомына, җәмәгать туклануы предприятиесенә, район элемтә узелына, туганнарыбыз, якыннарыбыз, күршеләребезгә чын күңелдән рәхмәтебезне белдерәбез.

Хатыны, балалары, оныклары һәм туганнары.

Кизләү урта мәктәбенең 1993 елгы чыгарылыш класс укучылары, беренче укытучылары **Затия Нуриәхмәт кызы Хөснетдинованың** тормыш иптәше Рәшит Нургата улының вакытсыз вафат булуы сәбәпле тирән кайгысын уртаклашалар.

Октябрь район кулланучылар җәмгыятенең азык комбинаты әнисе үлү сәбәпле **Төхфәтуллин Ильяс Исмәгыйль** улының тирән кайгысын уртаклаша.



С.МАЙСТЕР ФОТОСЫ

ЭЧ ӘЛЕ,СЫЙЛАН ӘЛЕ...

**Язучы блокнотыннан**

# Яңа сынамыш

- Карчык, вареньең ни хәлдә?

- Акрынлап ясыйм. Син, Кузя, карлыган җыярга булышыр идең.

- Нәрсәдер бармаклар бөгелми әле.

- Менә кайда ярап куяр иде оныгыбыз Верочканың җитез куллары. Сагындым да үзен.

- Мин дә. Тиздән ул безгә килә инде.

- Син хат алдың мәллә?

- Алар хат язалармыни?

- Кайтасын ничек белдең соң?

- Иртәгә безнең чират.

- Нинди чират?

- Нинди - нинди... Пенсия китерергә. Пенсия - ул төгәл сынамыш.

- Һәм яхшы тарту чарасы ла,- дип көлеп җибәрделәр икесе дә.

**Ф.САВГАЧЕВ.**

ТИМЕР ЮЛЧЫЛАР БИСТӘСЕНДӘ

# Торбасы бар - газы юк

Сезгә тимер юлчылар микрорайонынннан язалар. Безнең Калинин, Димитров, Энгельс, Гоголь урамнарына кайчан газ үткәрелер икән? Терәкләрне 2 - 3 ел элек куйганнар иде инде. Яз көнне торба суза башладылар. Без шатланышып,берәр миллион акчабызны да түләп куйдык,газ хисаплагыч та алдык.Түләүчеләргә торба суздылар сузуын,әмма анда газы булмагач ни файда.

**Халык исеменнән-Л.Федорова.**

# 6 ел көтәбез

Куйбышев урамындагы йортларны ремонтларга тиешле оешманы табарга булышсагыз иде. Эш шунда: 10 нчы НГЧ безнең йортны МППга ремонтланмаган түбәләр белән тапшырган иде. 6 елга кадәр җитәкчелек 35 нче йорт түбәсен ремонтларга вәгъдә бирде, аны ремонтлаган рәвеше ясап та карады. Ә ремонтчылар исә вакытлыча «ямау» салып, аны тимер чыбыклар белән беркетеп кенә куйдылар, түбәдән су агуын дәвам итте... Яңа оешмага без ике тапкыр заявка бирдек инде, әмма нәтиҗәсе генә юк. Безне кем кайгыртыр икән?

**Куйбышев урамындагы 35 нче йорттан Силаева, Лапшина, Иванова, Варламова һ.б.**

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2336 данә.